Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге составына керүче Песәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

2023 елның 22 ноябере № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 4 октябрендәге 122 номерлы карарына таянып, 2023 елның 22 ноябрндә 16.00 сәг. узган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнар җыенының «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Песәй авылы җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларын, төзәтү колонияләрендә җәза үтүчеләрне түләүдән азат итәргә һәм үзара салымның алынган акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- юлларны кардан чистарту;
- вак таш сатып алу;
- вак ташны тигезләү;
- мәктәп территориясе периметры буенча койма тоту;
- Яшьләр һәм Тукай урамына видео күзәтү камералары урнаштыру;
- мәктәп территориясендә биек агачларны кисү;
- санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәтләр;
- авыл җирлеге исеме белән Стелла урнаштыру;
- Сабантуй бәйрәмен үткәрү мәйданчыгында сәхнә кую:
- гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту ( үлән чабу);
- узган еллардагы калган калдыкларны юлларны чистартуга җибәрү.» - өчен сез ризамы дигән сорауга йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 292 граждан кертелде,

җыенда һәм тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 160

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча граждannar җыенында катнашучыларның табышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе" 160 граждан тавыш бирде;
"Юк" 0 граждан тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнары җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ

1. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Песәй авылы җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларын, төзәтү колонияләрендә җәза үтүчеләрне түләүдән азат итәргә һәм үзара салымның алынган акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- юлларны кардан чистарту;
- вак таш сатып алу;
- вак ташны тигезләү;
- мәктәп территориясе периметры буенча койма тоту;
- Яшьләр һәм Тукай урамына видео күзәтү камералары урнаштыру;
- мәктәп территориясендә биек агачларны кисү;
- санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәтләр;
- авыл җирлеге исеме белән Стелла урнаштыру;
- Сабантуй бәйрәмен үткәрү мәйданчыгында сәхнә кую:
- гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту ( үлән чабу);
- узган еллардагы калган калдыкларны юлларны чистартуга җибәрү-“ сез ризамы дигән сорауга карарны танырга.

3. Әлеге карарны Песәй авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Песәй авыл
җирлеге башлыгы В.И. Мөхәммәтгалиев